**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Атабай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

27 нче ноябрь 2023 ел № 4

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 нче елның 27 нче ноябрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Атабай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, олешчэ мобилизациядэ булганнар хэм аларнын гаилэ эгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 1700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карау (шул исәптән вак таш сатып алу, ташу, салу, кышын юлларны чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
2) торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән җәйге вакытта территорияне чуп улэннэреннэн чистарту, КРН-2,1 ротацияле косилкасының запас өлешләрен сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
3) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (шул исәптән янгын гидрантларын карап тоту, люкларны кардан һәм боздан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 47 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 29 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 29 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге составына керүче Атабай авылы халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Атабай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, олешчэ мобилизациядэ булганнар хэм аларнын гаилэ эгьзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 1700 сум күләмендә үзара салым кертергә. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карау (шул исәптән вак таш сатып алу, ташу, салу, кышын юлларны чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
2) торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән җәйге вакытта территорияне чуп улэннэреннэн чистарту, КРН-2,1 ротацияле косилкасының запас өлешләрен сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
3) беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тээмин итү (шул исәптән янгын гидрантларын карап тоту, люкларны кардан һәм боздан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

3. Әлеге карарны Иске Казиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru), кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Сагьдиев